**КУГАРЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**422662, с. Кугарчино, ул. Советская, дом 62а**

**БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КҮГӘРЧЕН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
**422662, Күгәрчен авылы, Совет урамы, 62а йорт**

Тел.: (84361) 28-589, факс: (84361) 28-589, эл.адрес: Kugar.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Күгәрчен ав. № 1 2021 елның 18 ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен һәм Зәнгәр- Күл авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы " Кәгәрчен авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен һәм Зәңгәр-Күл авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 29 ноябрендә 10 сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 29 ноябрендә 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 29 ноябрендә10 сәг. 00 минутка билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 30 ноябрендә 13 сәг. 00 минутка билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 30 ноябрендә 15 сәг. 00 минутка билгеләргә

6. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә кирәк.

7. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен һәм Зәңгәр-Күл авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, беренче төркем инвалидларыннан , бөтенләй ялгыз яшәүче 80 яшькә җиткән пенсионерлардан тыш, аларнын саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми саныннан 30 проценттан артып китә алмый, 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

1. Күгәрчен авылында Гагарин, Зәңгәр-Күл авылында Куйбышев урамы буенча юлларга вак таш сатып алу һәм ремонт ясау;
2. мәктәпкәчә төркем балалары өчен мәйданчыкны төзү
3. Күгәрчен авылында су торбаларын ремонтлау;
4. Күгәрчен һәм Зәңгәр Күл авыллары торак пунктларында юлларны кышкы чорда карап тоту;
5. су белән тәэмин итү системаларын рәсмиләштерү өчен .

ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күгәрчен авылы, Совет урамы,62 А йорт; адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге башлыгы: А.Т.Сафин